“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе”
дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе

Педагогик
киңәшмә утырышында каралды
“29”август 2022 ел. №1
Интернат мәктәбе директоры
_______________Л.Р.Мартынова
Боерык белән кертелде №98-0
“ 31 ” 08 2022 ел

**12нче ГОМУМБЕЛЕМБИРУ** сыйныфы өчен
**туган (татар) теленнән уку предметы буенча**
**эш программасы**
Атнага **0,5** сәгать**,** елга **34_** сәгать

Төзүчесе:
**татар теле һәм әдәбият укытучысы Мөхәммәтҗанова Л.Ф.**

Килешенгән:
Директор урынбасары________И.Б.Шарифуллина

МБ утырышында каралды, беркетмә№1 “26 ”август 2022 ел
МБ җитәкчесе ___________М.Г.Шәрипова

Әлмәт 2022 ел

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге **документларны** исәпкә алып төзелде:

**Эш программасы статусы.**

1. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (21.12.2012, №273-ФЗ)
2. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы Законы (25.10.1991, №1807-1, ред.12.03.2014)
3. Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы боерыгы 5.03.2004 №1089.
4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Инвалид балаларны өйдә тәрбияләү һәм укыту тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында" 16.06. 2008 ел, 401 нче карары.
5. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (22.07.2013, № 68-ЗРТ)
6. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (8.07.1992, №1560-XII; ред. 12.06.2014№53-ЗРТ)
7. Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы(1 — 11 нче сыйныфлар) /Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан:2018
8. Әлмәт интернат мәктәбендә дисциплина, предмет, уку курсларының эш программалары раслануы, эшләү тәртибе, структура нигезләмәсе 31.08.22 № 98-О.
9. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына программасы.
10. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына базислы уку-укыту планы.
11. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы турында нигезләмә (локальный акт).

- Үрнәк программа: Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы. Төп гомуми белем бирү мәктәбе / Төзүче-авторлар: Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан, 2013. (http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263450.docx).
- Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1-11 нче сыйныфлар)/ Төзүче-авторлар: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. – Казан, 2014.

(http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2)

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе; Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы 273 нче номерлы федераль законы; “Безнең яңа мәктәп” милли белем инициативасы; урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) ; “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы законы ; рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы. (1-11 нче сыйныфлар), Казан: Татар китап нәшрияты, 2014.Төзүчеләр: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән); “Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең төп гомуми белем бирү өчен (3 нче баскыч) программасы, / Төзүче-авторлары – Р.З. Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан, 2013 нче ел; ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Татар теле һәм әдәбияты фәннәреннән үрнәк программаларны раслау турында” № 933 //14 номерлы (24.02.2014) боерыгы; ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында” 12138/13 номерлы (7.09.2013 һәм 04.09.2014) хатлары.

Дәреслек: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. Татар теле. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) - Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2010 нчы ел.

## Татар телен укыту максатлары:

Урта һәм югары баскычларда рус телле балаларга татар телен укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

### **Танып белү максатының эчтәлеге**:

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Югары баскычта укучылар 1-9 сыйныфларда алган белемнәрен тагын да тулыландыралар, киңәйтәләр, гомумиләштерәләр. Урта баскычта өйрәнелгән темаларга өстәп, укучыларны Татарстанның сәнәгый-икътисади, фәнни һәм мәдәни үсеше, халыкара элемтәләре, Россиядә һәм дөнъяда тоткан урыны, Татарстанның югары уку йортлары, Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм спорт казанышлары турында иркен аралашуга чыгару максат итеп куела.

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда, бу максатлар беренче планга куела.

Югары баскычта балаларның психик үсешен фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив һәм дедуктив фикер йөртүне үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә.

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алынды: эчтәлегендә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый. Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырыла, сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары тәкъдим ителә.

**Бурычлар:**

- укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерүне дәвам итү;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирергә өйрәтү ;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү,
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.
- аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль куллануын тәэмин итү.

## УКЫТУНЫҢ ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ, ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятләргә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Урта гомуми белем бирү баскычында татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– коммуникатив компетенция, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашуга әзер булу;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
– “Татар теле һәм әдәбияты” фәненә карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру, шулай ук тиешле гомуми һәм махсус күнекмәләр формалаштыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре:**

Урта гомуми белем бирү баскычын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә карата, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләр формалашкан булу күзаллана: әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш

ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү; *әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;* шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре:**

Урта белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен, формалаштыруга хез-мәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган гипермедиалы мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда компьютер яисә ИКТ ның башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алулары формалаша.

**Уку елы башына укучыларның гомумбелем һәм фән буенча белем күнекмәләренә характеристика**.

Укучылар төрле килештәге тартымлы исемнәрне, шарт фигыльне, теләк фигыльне, боерык фигыльне, хикәя фигыльнең барлык заманнарын да сөйләмдә дөрес кулланалар; асыл сыйфатларны чагыштыру, артыклык дәрәҗәләрендә дөрес әйтәләр; микъдар, тәртип, җыю саннарын кулланалар; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгели беләләр; сөйләмдә кереш сүзләрне кулланалар.Укучылар якынча кушма җөмләләрнең төрләрен беләләр.

**Уку елы дәвамында формалаштырырга тиешле белем һәм күнекмәләр**.

Курс телдән һәм язмача аралашу темаларына бүлеп өйрәнелә.Программада сөйләмнең орфоэпик, интонацион, орфографик ягын, лексик ягын, грамматик ягын үзләштерүгә таләпләр куелган. Сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтүгә таләпләр төгәл һәм ачык билгеләнгән. 10 нчы класста морфология, синтаксис өйрәнелә , грамматик категорияләр, материал тулыландырыла, кызыклы мәгълүматлар белән баетыла. Татар теленә өйрәткәндә предметара бәйләнеш әһәмиятле урын тота: география, тарих, рус теле һәм башка фәннәрне кулланып укыту дәресне эчтәлекле һәм мавыктыргыч итеп оештырырга мөмкинлек бирә.

Укучылар 10 нчы класста татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү өстендә эшне дәвам итәләр; дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру, татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү өстендә эшлиләр.

Грамматикадан укучылар составы буенча җөмлә төрләрен ( бер составлы җөмлә төрләрен аера белү, төзи белү, кулланышка кертү), затланышлы, затланышсыз фигыльләрне аңлап аеру; тезмә фигыльләрне сөйләмгә кертү; сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа исемнәр, рәвешләр ясау; сөйләмдә алмашлыкларның төрле төркемчәләрен дөрес куллану өстендә эшлиләр. Бәйлекләрнең төрле килештәге исемнәр белән кулланышын үзләштерәләр, бәйлек сүзләрне төрләндереп җөмләләр төзиләр.

1992 нче елның 8 нче июлендә “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде Аның нигезендә татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып расланды. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән махсус программа буенча укытыла. Татар теленә уку программасы буенча 34 сәгать бирелә. Эш программасы белем бирү учреждениесенең гамәлдәге уку планы буенча атнага 1 сәгать исәбеннән төзелде.

**Кереш аттестация грамматик биремле контроль диктант формасында, I нче яртыеллык өчен йомгаклау аттестациясе, арадаш аттес-тация контроль эш (тест) формасында еллык календарь графикка туры китереп үткәрелә.**

Татар теленнән эш программасы түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрдән, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән, көтелгән нәтиҗәләрне исәпкә алып төзелгән календарь-тематик планнан, укучыларның белем һәм осталык күнекмәләрен бәяләү нормаларыннан, мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары исемлегеннән.

**Эш программасына кертелгән үзгәрешләр**

Элек үтелгән фигыль төрләре тагын кабатланып кителә: сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, теләкне белдерүнең төрле формалары, фразеологизмнар, фигыльнең заман формалары үтелә. Грамматик материал мисалларда ныгытылып, иркен сөйләм теленә җиткерелә.

## БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕНӘ ТАЛӘПЛӘР:

1. Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен гамәли белү.

2. Татар телендә сүз басымының үзенчәлекле очракларын белү һәм аерым грамматик формалардагы сүзләргә басымны дөрес куя белү.

3. Иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тотып сөйли алу: *күк-күге, кунак-кунагым, тап-таба, тек әле- /тэгэлэ/*

4. Татар сөйләмен синтагмаларга бүлә һәм логик басымның җөмләдәге урынын билгели белү.

5. Кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес куллана һәм яза белү.

6. Антоним, синоним, омонимнарны аера белү һәм сөйләмдә урынлы куллана алу.

7. Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төрле сүзлекләрдән файдалана белү.

8. Лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен,башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.

9. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү.

10. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү.

11. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белү. (*Бүген безгә* ***кунаклар*** *килә. Кунаклар безгә* ***бүген*** *килә. Кунаклар бүген* ***безгә*** *килә.)*

12. Иярченле кушма җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләрен гамәли куллана белү.

13. Бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алу.

14. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре (өтер, ике нокта, сызык ).

## ПРОГРАММАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать саны | Темага караган төп төшенчәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Алда юллар, кайсын сайларга? | 12 | Татар телендә авазлар системасы, җөмлә кисәкләре, исем, аның килеш белән төрләнеше, хикәя, сыйфат, шарт фигыльләр, зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, бәйлек сүзләрнең ясалышы, теләкне белдерүнең “Барасым килә (килми)” формасы |
| 2 | Татарстан Республикасы | 4 | Сан төркемчәләре, фигыль төркемчәләре, исем ясагыч кушымчалар, билгеле киләчәк заман хикәя фигыль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Гаилә һәм балалар | 8 | Исемгә кушымчалар ялгау тәртибе, исемнең 2нче төрләнеше, билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, рәвеш төркемчәләре, иярченле кушма җөмләләр, кисәкчәләрнең төркемчәләре |
| 4 | Мәхәббәт – гаиләнең нигезе | 10 | Исем фигыль, аның килеш белән төрләнеше, инфинитив, боерык фигыльнең төрләнеше, бәйлек сүзләр, теркәгечләр, кушма җөмлә төрләре |
| | Барлыгы | 34 сәгать . | |

| Т/с | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Предмет нәтиҗәләре | | Гомумкүнекмәләр һәм уку эшчәнлеге ысуллары | КИМ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Календарь | фактик | Белем | Күнекмә | | |
| **I яртыеллык (16 сәгать)** | | | | | | | | |
| **Алда юллар, кайсын сайларга (12 сәгать)** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Система звуко на татарском языке.<br>Татар телендә авазлар системасы | 1 | 01.09 | | Язу һәм укуның төп кагыйдәләрен программада бирелгән сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын белү | Сүзләрнең транскрипциясен дөрес язу, татар теленең барлык авазларын дөрес әйтә белү | Таблица белән эшләүне камилләштерүне дәвам итү | |
| 2 | Виды спряжения глагола изъявительного наклонения.<br>Хикәя фигыльнең заман формалары | 1 | 08.09 | | Хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләрен белү | Үткән һәм киләчәк заманның төрле форма ларын сөйлә мдә куллану | Фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү, татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавын төшенү | |
| 3 | Члены предложения.<br>Җөмлә кисәкләре | 1 | 15.09 | | Җөмлә кисәкләрен искә төшерү | Булган белемнәрне практикада куллану | Үзалдына эшләүне күнектерү | |
| 4 | Функция падежей у существительных.<br>Исемнең килешләр функциясе | 1 | 22.09 | | Исемнәрнең килешенә карап җөмлә кисәкләрен аеру, татар телендә исемнең род категориясе булмавын белү | Төрле килештә иркен рәвештә җөмлә төзү | Дәреслектәге кагыйдәне мөстәкыйль үзләштерү | |
| 5 | Формы изъявительного наклонения.<br>Теләк белдерү формалары | 1 | 29.09 | | “эшлисе килә” конструкциясе ярдәмендә теләк белдерүне аңлау | Үз теләгеңне төрлечә белдерә алу | Диалогик сөйләмне үстерү | |
| 6 | Повторение сложных предложений.<br>Кушма җөмлә төрләрен кабатлау | 1 | 06.10 | | Кушма җөмлә төрләрен кабатлау | Дөрес язу күнекмәләре бирү | Грамматик биремле диктант язу | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| 7 | Причастие.<br>Сыйфат фигыль | 1 | 13.10 | | Сыйфат фигыльнең заманнарын ясый белү | Сөйләмдә сыйфат фиг. куллану | Төркемнәрдә эшләү | |
| 8 | Положительная и отрицательная форма причастия.<br>Шарт фигыльнең барлык, юклык формасы | 1 | 20.10 | | Шарт фигыльнең ясалышын аңлап, дөрес төрләндерү | Сөйләмдә шарт фигыль куллану | Төркемнәрдә эшләү | |
| 9 | Окончания падежей у личных местоимений.<br>Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше | 1 | 27.10 | | Зат алмашлык-ларының берлек һәм күплек санда килеш белән төрләнешен искә төшерү | Зат алмашлыкла-рын төрле килеш-ләрдә сөйләмдә куллана алу | Практик эшне башкаруны тәэмин итү | |
| 10 | Деепричастие.<br>Хәл фигыль | 1 | 10.11 | | Хәл фигыльнең формалары кайчан кулланылуын аңлау | Хәл фигыльнең төрле формаларын дөрес куллану | Таблица белән эшләүне күзәтү | |
| 11 | Словообразование союзов.<br>Бәйлек сүзләрнең ясалышы | 1 | 17.11 | | Бәйлек сүзләрнең нинди тамырдан ясалуын төшенү, | Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң килүен белү, аларны дөрес куллану | Үз эшеңне бәяли белү | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Повторение раздела “Выбор профессии – ответственная работа”. “ Һөнәр сайлау – җаваплы эш” бүлеген кабатлауга | 1 | 24.11 | | Кирәкле лексиканы сайлый белү | Исем фигыльнең төрләнешен сөйләмдә куллану | Һөнәр сайлау турында сөйләшү, анкета сорауларына җавап бирү | |
| **Татарстан Республикасы (4 сәгать)** | | | | | | | | |
| 13 | Разделы числительных. Сан төркемчәләре | 1 | 01.12 | | Сан төркемчәләрен искә төшерү, саннарның исем янында төрләнмәвен белү | Саннарны диалогта куллану | Иптәшең нең эшен анализларга өйрәтү | |
| 14 | Использование в письме глаголов. Язуда фигыльләрне дөрес куллану | 1 | 08.12 | | Кагыйдәләрне дөрес куллану | Язуда затла-нышлы, затла-нышсыз фигыль-ләрне дөрес кул-лану | Иптәшең нең эшен анализларга өйрәтү | |
| 15 | Словообразующие окончания существительных. Исем ясагыч кушымчалар | 1 | 15.12 | | Киң таралган сүзләрнең ясалышын аңлау | Билгеле кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау | Китап белән мөстәкыйль эшләүне күзәтү | |
| 16 | Определенное будущее время глагола изъявительного наклонения. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыль | 1 | 22.12 | | Кушымчаларны дөрес ялгый белү, рус теле белән чагыштыру | Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллану | Монологик сөйләмне үстерү | |
| **II яртыеллык (18 сәгать)** | | | | | | | | |
| **Гаилә һәм балалар (8 сәгать)** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Порядок присоединения окончания у существительных.<br>Исемгә кушымчалар ялгау тәртибе | 1 | 12.01 | | Исемгә күплек, тартым, килеш кушымчаларын ялгый белү. | Кушымчаларны дөрес куллану. Микъдар саны белән янәшә килгәндә, исемнәрнең сан белән төрләнмәвен белеп, сөйләмдә дөрес куллану | Дәреслек белән эшли белү кунекмәләрен камилләштерү | |
| 18 | Известный писатель Разиль Валиев.<br>Танылган шагыйрь Разил Вәлиев | 1 | 19.01 | | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | План төзү һәм шуның нигезендә эзлекле фикер йөртеп, сөйләмгә чыгу | |
| 19 | Склонение существительных.<br>Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | 26.01 | | Татар телендә исемнең тартым категориясе булуын һәм аның рус телен-дә бирелешен аңлау | Практикада тартымлы исемнәрне хатасыз куллану | Таблица белән эшләүне камил - ләштерү | |
| 20 | Спряжение глаголов определенного будущего времени изъявительного наклонения.<br>Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | 1 | 02.02 | | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль-нең мәгънәви үзен-чәлеген аңлау, вид категориясе булма-вын белү, төрлә-нешне истә калдыру | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәви үзенчәлеген аңлап, диалогта куллану | Дәреслек белән мөстәкыйль эшләү | |
| 21 | Виды наречия.<br>Рәвеш төркемчәләре | 1 | 9.02 | | Рәвеш төркем-чәләрен аңлау, тәр-җемә итү, рус телен-дәге рәвешләр белән чагыштыру | Җөмләләрдә иркен куллану | Төркемнәрдә проект эшләре башкару | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Сочинение “В здоровом теле – здоровый дух”. Сочинение “Сәламәт тәндә-сәламәт акыл” | 1 | 16.02 | | Бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү | Дөрес язу күнекмәләре бирү | Хәтерне үстерү өстендә эшләү | Сочинение |
| 23 | Сложное придаточное предложение. Иярченле кушма җөмләләр | 1 | 23.02 | | Иярчен кушма җөмләләрнең киң кулланылышта йөргән аналитик һәм синтетик төрләрен: вакыт, урын, максат, сәбәп, шарт, кире җөмләләрне истә калдыру | Ирченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләреннән файдалана алу | Синтетик иярчен җөмләләрнең һәрвакыт баш җөмлә алдыннан килү үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оешыра алу | |
| 24 | Виды частиц. Кисәкчәләрнең төркемчәләре | 1 | 02.03 | | Татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив һәм постпозитив булуын белү | Һәр төркемчәдәге кисәкчәне куллана белү | Тәрҗемә итү, сорауларга җавап бирү | |
| **Мәхәббәт – гаиләнең нигезе (10 сәгать)** | | | | | | | | |
| 25 | Использование в предложении имя действия. Исем фигыльне җөмләдә куллану. | 1 | 9.03 | | Исем фигыльнең баш килешенең кулланышын аңлау | Исем фигыль формаларын аңла п куллану | Җөмләләр төзү | |
| 26 | Повторени частей речи. Сүз төркемнәрен кабатлау. | 1 | 16.03 | | Сүз төркемнәре турындагы белемнәрне ныгыту | Төрле төөркемгә караган сүзләрне сөйләмдә куллану | Грамматик кагый-дәләрне дөрес куллану | |
| 27 | Инфинитив. Инфинитив | 1 | 23.03 | | Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану | Модаль сүзләр һәм аерым фигыльләр белән инфини-тивны куллану | Киңәш бирү сәләтен үстерү | |
| 28 | Словарный диктант. Сүзлек диктанты | 1 | 06.04 | | Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң | Бәйлек сүзләрне юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт | Бәйлек сүзләрне дөрес язу күнекмәләре бирү | Сүзлек диктанты |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | килүен белү | килешендә куллану | | |
| 29 | Спряжение глаголов повелительного наклонения.<br>Боерык фигыльләрнең төрләнеше | 1 | 13.04 | | 3нче затта боерык фигыльнең ясалышын, мәгънәсен аңлау | Татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавын аңлап куллану | Хаталар өстендә кунегүләр эшләү | |
| 30 | Виды сложных предложений.<br>Кушма җөмлә төрләре | 1 | 20.04 | | Кушма җөмләләрдә тезүле һәм ияртүле бәйләнеш, аларны аера белү | Тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану | Кушма җөмләләр төзүне камилләштерү | |
| 31 | Союзы.<br>Теркәгечләр | 1 | 27.04 | | Тезүче һәм ияртүче теркәгечләрне аеру, аларны җөмлә төзегәндә куллана белү | Җөмлә төзегәндә теркәгечләрне дөрес куллану | Сүзлек запасын баету өстендә эшләүне дәвам итү | |
| 32 | Повторение сложносочиненных и сложноподчиненных предложений.<br>Тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | 04.05 | | Кушма җөмлә төрләрен аера белү | Иярченле кушма җөмләләрне ике юл белән төзү | Җөмләләр тикшерә белү | |
| 33 | Повторение пройденного материала в 12 классе.<br>12нче сыйныфта үткән материалны кабатлау | 1 | 11.05 | | 12нче сыйныфта үткән материалны кабатлау һәм йомгаклау | Мөстәкыйль эшли белүне камилләштерү | Тест сорауларына җавап бирү | |
| 34 | Заключение.<br>Йомгаклау | 1 | 18.05 | | Пландагы эшләренңне дөрес әйтергә өйрәнү | Өйрәнелгән лексиканы сөйләмдә куллану | Күнегүләр эшләү | |

## ЯЗМА ЭШЛӘРНЕ ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ.

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен, татар теле дәресләрендә төрле язма эшләр үткәрелә.

Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар теленнән язма эшләр ике төркемгә бүленә:

1)өйрәтү характерындагы эшләр (изложение, сочинение);

2)контроль эшләр (сүзлек диктанты; хәтер, күрмә, иҗади диктантлар)

### Сүзлек диктанты һәм аны бәяләү.

**12 нче класста 28-30 сүз.**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә “5”ле куела.
Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булган эшкә “4”ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4-5 төзәтүе яки 3-5 орфографик хатасы булган эшкә “3”ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

**Язма сөйләмне тикшерү һәм бәяләү.**

Укучыларның бәйләнешле язма сөйләм күнекмәләре өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр ярдәмендә тикшерелә. Алар белән беррәттән башка язма эшләр дә куллана: сорауларга язмача җавап бирү; рус теленнән татар теленә текстларны язмача тәрҗемә итү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген язмача сөйләп бирү(изложение); бирелгән ситуация яки тәкъдим ителгән тема буенча фикерләрне язмача белдерү(сочинение) һ.б. Язма сөйләмне бәяләгәндә, эчтәлекнең тулылыгына һәм эзлеклегенә, җөмлә калыпларының грамматик яктан дөреслегенә һәм төрлелегенә, стиль бердәмлегенә игътибар итәргә кирәк. Изложение һәм сочинение өчен ике билге куела: беренчесе эшнең эчтәлеге өчен, икенчесе – грамоталы язуга.

**12 нче класста уку елы башында 175-180 сүз, уку елы ахрында 190-210 сүз.**

Тыңланган текстның эчтәлеге тулы, эзлекле һәм дөрес язылган,1 орфографик, 1 пунктуацион яки 1 грамматик хатасы булган эшкә “5”ле куела.
Тыңланган текстның эчтәлеге эзлекле һәм дөрес язылган, ләкин 1-2 эчтәлек ялгышы җибәрелгән, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион яки 2-3 грамматик хатасы булган эшкә “4”ле куела.
Тыңланган текстның эчтәлеге өлешчә эзлекле язылган, 4-5 орфографик, 4 пунктуацион яки 4-5 грамматик хатасы булган эшкә “3”ле куела.
Тыңланган текстның эчтәлеге бөтенләй ачылмаган, эзлекле язылмаган, 6 дан артык орфографик, 5 тән артык пунктуацион яки 6 дан артык грамматик хатасы булган эшкә “2”ле куела

**Сочинениеләрне бәяләү.**

**11нче класста 13-15 җөмлә**

Сочинение укучыларның тормыштагы күзәтүләреннән алган тәэсирләрен язмада грамоталы һәм эзлекле бирә белү, әдәби әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән образлы телдә бәйләнешле итеп яза алу мөмкинлеген тикшерү максатыннан яздырыла. Алар укучыларның тел һәм әдәбият дәресләрендә алган белемнәрен ныгыту, тирәнәйтү һәм камилләштерүне күздә тотып үткәрелә.
Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган һәм эчтәлеге тулы ачылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булган эшкә “5”ле куела.
Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хатасы булган эшкә “4”ле куела.

Тәкъдим ителгән темага өлешчә эзлекле язылган, эчтәлеге тулысынча ачылмаган, 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион һәм җөмлә төзелешендә хаталары булган эшкә “3”ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган , 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хаталары булган эшкә “2”ле куела.

## МӘГЪЛҮМАТҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЧЫГАНАКЛАРЫ

| **УМК** | **Укытучы өчен методик әдәбият** | **Укучылар өчен әдәбият** |
|---|---|---|
| Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева “ Татар теле-11” Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010ел<br><br>кассеталар, таблицалар, индивидуаль карточкалар, татар язучыларының портретлары, магнитофон һ.б<br><br>Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы, Казан, 2010ел, | 1 .Хисаметдинова Р.Ф.җитәкчелегендәге иҗади төркем, укыту-методик кулланма,Яр Чаллы, 2006 ел<br><br>2. Д.Т.Гыйльманова, Укыту-методик кулланма, Яр Чаллы, 2006<br><br>3. Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов “Татар әдәбияты” Казан, 2007<br><br>4. Д.Ф.Заһидуллина “Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы” Казан, 2007<br><br>5. Р.З.Хәйдарова “ Научно- педаго гические аспекты билингвального образования в РТ” Н Челны, 2007<br><br>6. Ф.Ф.Харисов “Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре” Казан, 2006<br><br>7. Гомуми урта белем бирү мәктәпләренең | 1.Хәсәнова Н.М.”Татар телен өйрәнүчеләр өчен кагыйдәләр һәм күнегүләр җыентыгы” 1-2 нче кисәк, Яр Чаллы, 2003<br><br>2. Ф.С.Сафиуллина “ Базовый татарско-русский и русско-татарский словарь для школьников”Казань,ТаРИХ, 2007<br><br>3. Программа буенча каралган язучыларның әсәрләре<br><br>4. “ Татарстан яшьләре”, Шәһри Чаллы” газеталары, “Мәйдан”, “Казан утлары” журналлары)<br><br>5. Байрамова Л.К, Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь, Казань,1991г<br><br>6..Ф.С.Сафиуллина,К.Р.Галиуллин, Тематический русско-татарский словарь,1989 |

| | | |
|---|---|---|
| | 10-11нче сыйныфында укучы рус телле балаларга татар теленнән контроль эшләр, Яр Чаллы,2010 ел.<br><br>8. Н.Хәбибуллина, М.А.Вәлиуллин, Х.Г.Фәрдиева, V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр,Казан, 2003ел.<br><br>9. Ә.Б.Шакирҗанова, Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы, 2008 ел.<br><br>10. Краткий справочник и упражнения по синтаксису сложноподчинённого предложения татарского языка., Набережные Челны, Нигматуллина Р.М.<br><br>11 Халык авыз иҗатын өйрәнү өчен өстәмә материаллар, Яр Чаллы, 2007 ел. Гарифуллина.<br><br>12. М.З.Закиев, Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибрагимов, К.З. Зиннатуллина, Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков, Казань, Татарское книжное издательство, 2007 год.<br><br>13. Таар теленнән кагыйдәләр җыентыгы, Казан, “Гыйлем” нәшрияты, 2008ел. | 7.Н.Исәнбәт, Татар теленең фразеологик сүзлеге, Казан, 1990ел.<br><br>8. Х.Г.Агишев, Л.Х.Гайнуллина, Русско-татарский словарь словосочетаний для учащихся,, Казань, 2002год.<br><br>9. К.Р.Галиуллин, Р.И.Раскулова,Татар теленең орфографик сүзлеге, Казан,2010ел.<br><br>10.Сайдаш Гарифуллин, Послеслоги татарского языка, Набережные Челны, 1993год. 29) Ф.А.Ганиев, Ф.Ф,Гаффарова, Русско –татарский словарь, Казань, 2001год.<br><br>11.Ф.С. Сафиуллина,Ф.М.Газизова,татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге.<br><br>12.В.Х.Хаков, А.И.Латыпова, С.Д.Бакирова, Т.Р.Шакирова, Товар турында мәгълүмат укыйбыз.<br>13.Ш.С.Ханбикова,Ф.С.Сафиуллина, Синонимнар сүзлеге, Казан, 1999 ел.<br><br>14.К.С.Фәтхуллова, Э.Н.Денмөхәммәтова, Татар теленнән олимпиадага әзерләнәбез, Казан,2009 ел. Татар телен өйрәнүчеләр өчен кагыйдәләр һәм күнегүләр җыентыгы,Яр Чаллы, 2009, ХәсәноваН.М.<br><br>15.Ф.С.Сафиуллина,Л.М.Ризванова, |

| | | |
|---|---|---|
| | 14 Н.Г.Гәрәева, Н.В.Максимов. Ә.Ә.Зыятдинова.,Тел- белемнең ачкычы, Татар теле һә сөйләм үстерү дәресләре, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2005 ел. | Татарча-русча антонимнар сүзлеге , омонимнар сүзлеге,Казан,1997 ел.<br><br>16.Ф.С.Сафиуллина, К.Р. Галиуллин, Русско-татарский разговорник,1986 г.<br><br>17.Ф.А.Ганиева,Татарско-русский разговорник, 1988ел. |

## Эш программасына төзәтмәләр кертү бите

| Класс | Дәрес темасы | План буенча үткәрү вакыты | Төзәтмәләр кертүнең сәбәбе | Төзәтмәләр кертү чаралары | Фактта үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |